ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№1102 от «18» 09 2017 г.

2017 елда Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районыда
муниципаль контроль органнары тарафыннан
гамәлгә ашырыла торган хокук бозуларны
профилактикалау программасын раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Әлеге карага кушымта булып бирелгән 2017 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыда муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хокук бозуларны профилактикалау программасын (алаг таба- хокук бозуларны профилактикалау программасы) расларга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының тиешле эшчәнлек өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затларына әлеге карарның 1 пункты белән расланган Хокук бозуларны профилактикалау программасын үз компетенциясе чикләрендә үтәүне тәэмин итәргә.

3. Муниципаль район башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.М.Дәрҗемановка йөкләргә.

Җитәкче И.Э.Фәттахов

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеттының
18.09. 2017 ел, № 1102 карарына
Кушымта

**2017 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыда муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хокук бозуларны профилактикалау**
**П Р О Г Р А М М АС Ы**

**I бүлек. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары гамәлгә ашыра торган муниципаль контроль төрләре**

| № п/п | муниципаль контроль төренең исеме | эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган (вазыйфаи зат) исеме |
|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** |
| 1. | Муниципаль җир контроле | Мамадыш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |
| 2. | Муниципаль урман контроле | Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |
| 3. | Муниципаль торак контроле | Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү секторы |
| 4. | Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль | Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| 5. | Җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контроль. | Мамадыш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |

**II бүлек. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары гамәлгә ашыра торган хокук бозуларны профилактикалау чаралары**

| № п/п | Чараларның исеме | Гамәлгә ашыру вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| 1. | Мамадыш муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми | IV квартал | Муниципаль контрольне гамәлгә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сайтында норматив хокукый актлар исемлекләренең яисә аларның мәҗбүри таләпләре булган, үтәлешен бәяләү муниципаль контроль предметы булган аерым өлешләренең, шулай ук тиешле норматив хокукый актлар текстларын муниципаль контрольнең һәр төре өчен урнаштыру | | ашыруга вәкаләтле органнар (вазыйфаи затлар) әлеге Программаның I бүлегендә күрсәтелгән эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә |
| 2. | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга мәгълүмат җиткерүне, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү, семинарлар һәм конференцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре һәм башка ысуллар белән җитәкчелек әзерләү һәм бастырып чыгару юлы белән гамәлгә ашыру.<br>Мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта - гамәлдәге актларга кертелгән мәҗбүри таләпләрне, аларны гамәлгә кертү срокларын һәм тәртибендә кертелгән үзгәрешләрне билгели торган яңа норматив хокукый актларның эчтәлеге турында шәрехләр әзерләү һәм тарату, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәүне гамәлгә кертүгә һәм тәэмин итүгә юнәлдерелгән тиешле оештыру, техник чаралар уздыру турында тәкъдимнәр | Ел дәвамында (кирәк булганда) | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар (вазыйфаи затлар) әлеге Программаның I бүлегендә күрсәтелгән эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә |
| 3. | Муниципаль контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыру практикасын даими рәвештә (елга кимендә бер тапкыр) гомумиләштерүне тәэмин итү һәм Мамадыш муниципаль районының «Интернет» челтәрендә рәсми сайтында тиешле гомумиләштерүләрне урнаштыру, шул исәптән мондый хокук бозуларны булдырмау максатларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан кабул ителергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән зарури таләпләрне бозуның иң еш очрый торган очраклары күрсәтелеп | IV квартал | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар (вазыйфаи затлар) әлеге Программаның I бүлегендә күрсәтелгән эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә |
| 4. | «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның | Ел дәвамында (кирәк булганда) | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар (вазыйфаи затлар) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 5 - 7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр бирү (әгәр федераль закон белән башка тәртип билгеләнмәгән булса) | | әлеге Программаның I бүлегендә күрсәтелгән эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә |

Җитәкче урынбасары И.М.Дәрҗеманов